| | |
|---|---|
| "Килешенде"<br>Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары: ________ М.Р.Зарипова<br>Беркетмә № 1<br>"25" август 2021 | "Раслыйм"<br>Мәктәп директоры:<br>________ З.И.Хайруллина<br>Боерык № 11<br>"27" август 2021 |

Татарстант Республикасы Арча муниципаль районы
МБГБУ "Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта гомуми
белем мәктәбе"нең I категорияле татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызының
9 нчы класс өчен "Ялкынлы каләм" түгәрәгенең
эш программасы

Педагогик киңәшмә утырышында кабул ителде
Беркетмә № 1, "27" август, 2021 ел

## Аңлатма язуы

Мәктәптә әдәбият – эстетик төркемгә керүче предметларның берсе. Матур әдәбият яшь буынны тәрбияләүгә булышлык итә, балаларның дөньяга карашын киңәйтә, белемнәрен тирәнәйтә һәм аларда мөстәкыйль эшләү күнекмәләре тәрбияли.

Әдәбият ул – сүз сәнгате. Әмма дәресләр чикле.Өстәмә белем бирү, әдәбиятта яңа исемнәр, аларның иҗаты белән танышу; туган якның әдәбият һәм журналистика әһелләрен, аларның иҗатын киңрәк өйрәнү һәм укучыларның иҗади сәләтләрен ачуны күздә тотып, дәрестән тыш эшләрне «Ялкынлы каләм» түгәрәгендә алып барырга булдым.

Укытучы буларак мин, «Халык педагогикасын кулланып, укучыларга белем һәм тәрбия бирү» дигән методик темага йөз тотып эшлим.

Түгәрәкнең планын төзегәндә һәр классның әдәбият программасы, укучыларның теләкләре һәм кызыксынулары искә алына.

“Ялкынлы каләм” түгәрәге сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен үстерү буенча класстан тыш эшләрнең нәтиҗәле формаларыннан берсе.

Беренче занятие оештыру эшләреннән башлана: түгәрәк әгъзаларының исемлеге төзелә, аның старостасы сайлана, планы түгәрәк утырышында тикшерелә һәм раслана. Занятиеләр аерым әсәрләрне уку яки сөйләүгә генә кайтып калмый. Анда әдәбият теориясенә (ритм, рифма, строфа, тема, төрле сурәтләү чараларына һ.б.) әһәмият бирелә. Дәрестә өйрәнгән кагыйдәләрне сорыйм һәм укучылардан мисаллар китертәм. Болар бар да түгәрәккә йөрүче укучыларның гамәли-иҗади эшләренә, шулай ук аларның иҗат эшләрен оештыруга, программа материалын тирәнрәк үзләштерүгә һәм әдәбият белән кызыксынуны көчәйтүгә ярдәм итә. Занятиеләрдә укучыларның иҗади эшләре тикшерелә, сәнгатьле уку күнекмәләре бирелә.

Түгәрәктә якташ язучы, шагыйрь, артистларыбызның иҗатын өйрәнеп, укучы күңеле туган як, аның хезмәт сөюче халкы, тормыш-көнкүреш вакыйгаларыннан алган тәэсирләр белән байый, горурлык хисләре арта. Дәрес вакытында өстәмә белем бирү чыганагы буларак та файдалы дип саныйм.

Өйрәнү өчен халык күңелендә лаеклы урын алган, мөһим эчтәлекле, бүгенге көндә актуаль булган, эстетик-социаль ихтыяҗларны кәнагатьләндерә алырлык яхшы әсәрләр сайлап алынды. Шуның белән бергә программага укучыларны мөмкин кадәр күбрәк язучылар белән таныштыру максатыннан әлегә әз таныш булган яшь язучыларның әсәрләре дә тәкъдим ителә. Әсәрләрне укытучы һәм укучыга сайлап алу мөмкинлеге дә тудырыла.

Программада төрле конкурслар, очрашулар да каралган. Елның һәр фасылында табигатькә экскурсияләр дә кертелде.

Бәйләнешле сөйләм үстерү, сәнгатьлелек, культуралы сөйләм кебек проблемалы мәсьәләләр дә программада урын алган. Шулай ук түгәрәктә шигырь, хикәя язу серләре белән танышкан укучы дәрестә әсәрләргә анализ ясаганда, үз көченә ышанып, язма эшләр вакытында тел-сурәтләү чараларыннан иркен файдаланып, иҗади фикерләү сәләтенә бай булуын күрсәтә.

Куелган максатлардан чыгып, түгәрәкнең программасы, занятиеләр тематикасы сайланды.

Занятиеләр укучыларның танып-белү һәм иҗади эшчәнлеген оештыруга корылган.

## Түгәрәкнең максаты

“Ялкынлы каләм” түгәрәге оештыруның төп максаты-сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен үстерүгә шартлар тудыру, укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, дине, татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, гомумән, күренекле шәхесләрен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

## “Ялкынлы каләм” түгәрәгенең төп бурычлары

Әлеге максатка ирешү юлында татар укучыларына әдәбият фәне буенча түгәрәк үткәрүнең төп бурычлары түбәндәгечә билгеләнә:

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, тел һәм әдәбият буенча иҗади сәләтен үстерү һәм иҗат итәргә омтылыш тудыру.

2. Балаларны мәктәп программасында булмаган, Арча районында яшәп иҗат итүче, халык арасында яратып укыла торган язучыларның аерым вәкилләре һәм аларның иҗат үрнәкләре белән таныштыру..

3. Районыбыз язучыларының иҗатын өйрәнү аша район, авыл тарихы, аның күренекле кешеләре, традицияләре белән танышу.

4. Тормышларын әдәбият дөньясына, журналистикага багышлаган укучыларны киләчәктә мөстәкыйль белем алуга, алган белемнәренә нигезленеп, укуларын югары уку йортларында уңышлы дәвам итәрлек укучылар хәзерләү.

**Әдәбият түгәрәгенең актуальлеге**

Якташ язучыларның иҗатларын, әсәрләрен өйрәнү мәктәп программаларында урын алмаган. Шуны исәпкә алып, мәктәптә “Ялкынлы каләм” түгәрәге оештырылды.

**Язучы иҗатын өйрәнү түбәндәге тәртиптә алып барыла:**

1. Язучының тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү.
2. Әдәби текстны гомуми тикшерү (укып фикер алышу).
3. Мөмкин булганда, язучылар белән очрашу үткәрелә.

**Үз белемеңне күтәрү**

Фән яңалыклары белән танышып бару.
Танылган кешеләр белән аралашу, очрашуларга бару.
Вакытлы матбугат белән даими танышу.
Театр, концерт, кичәләргә йөрү.
Семинар - конференцияләрдә катнашу, чыгыш ясау.
Тәҗрибә уртаклашу. Башка түгәрәкләр эше белән танышу, анализлау.

**Ата-аналар белән эш:**

Түгәрәккә йөрүче балаларның ата-аналары белән очрашу.
Ата-аналарны бәйрәм һәм кичәләргә чакыру.
Ата-аналар белән берлектә экскурсиягә баруны оештыру.

**Сәламәтлекне саклау:**

Укучыларның чиста һәм пөхтә йөрүләренә ирешү.
Дәресләр арасында тәнәфес ясау.
Ял минутлары уздыру.
Куркынычсызлык буенча инструктаж үткәрү.
Бүлмәнең саф, чиста, җилләтелгән булуын төгәл үтәү.

**Календарь – тематик план**

| № | Тема | Сәг. саны | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **План буенча** | **Факт буенча** | |
| 1 | Кереш дәрес. Оештыру эшләре:түгәрәк әгъзаларының исемлеген төзү,старостасын сайлау,планны бергәләп карау | 1 | | | |
| 2 | Истәлекле һәм онытылмас даталарны билгеләү, белешмә бирү. | 1 | | | |
| 3 | Болгарга сәяхәт ( презентация карау) | 1 | | | |
| 4 | Мәкалә язу (сәяхәткә багышлап) | 1 | | | |
| 5 | Әкиятләр уку, төрләрен өйрәнү, иҗат итү. | 1 | | | |
| 6 | Укучыларның иҗат эшләрен бергәләп тикшерү. Конкурсларда катнашу. | 1 | | | |
| 7 | Әдәби викторина. | 1 | | | |
| 8 | Балалар журналларына (“Ялкын”, “Сабыйга”һ.б.ш.) күзәтү ясау. | 1 | | | |
| 9 | Балалар газеталарына ( “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” һ.б.ш.) күзәтү ясау. | 1 | | | |
| 10 | Шигырь төзелешен өйрәнү : рифма, ритм.Рифманың шигырьдәге әһәмияте. Рифмадаш сүзләр табу. | 1 | | | |
| 11 | Сурәтләү чараларының әһәмияте. Сурәтләү чаралары – эпитет. | 1 | | | |
| 12 | Сурәтләү чаралары-гипербола. | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Сурәтләү чаралары – литота, метафора | 1 | | | |
| 14 | Сурәтләү чаралары – метанимия, сынландыру. | 1 | | | |
| 15 | Г.Тукай һәм М.Җәлил шигырьләренең үзенчәлеге | 1 | | | |
| 16 | Төрле темаларга (ел фасыллары, уеннар, сөю-сәгадәт...) шигырьләр язу. | 1 | | | |
| 17 | Иҗади эшләрне туплау. | 1 | | | |
| 18 | Сәнгатьле уку серләре: интонация, пауза | 1 | | | |
| 19 | Сәнгатьле уку серләре: басым, логик перспектива | 1 | | | |
| 20 | Сәнгатьле уку серләре: сөйләү техникасы | 1 | | | |
| 21 | Сәнгатьле уку серләре: сөйләү темпы, тавыш. | 1 | | | |
| 22 | Сәнгатьле укучыларны билгеләү бәйгесе | 1 | | | |
| 23 | Район олимпиадасына әзерләнү. | 1 | | | |
| 24 | Район олимпиадасына әзерләнү. | 1 | | | |
| 25 | Фәнни-гамәли конференциягә әзерләнү. | 1 | | | |
| 26 | Фәнни-гамәли конференциягә әзерләнү. | 1 | | | |
| 27 | Презентация төзү. | 1 | | | |
| 28 | Мәзәкләр, әкиятләр, кроссвордлар төзелеше б/н таныштыру, язарга тәкъдим итү, стенгазета чыгару | 1 | | | |
| 29 | Авылым мәзәкләрен җыю, туплау. | 1 | | | |
| 30 | Мәзәкләр иҗат итү. | 1 | | | |
| 31 | Мәкалә, аны ничек язарга? | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 32 | Мәкаләнең исеме, аның әһәмияте | 1 | | | |
| 33 | Газетада басылган мәкаләләргә күзәтү ясау, бәяләү. | 1 | | | |
| 34 | Мәктәп музеена экскурсия, мәкаләгә материал туплау, язу | 1 | | | |
| 35 | Мәкалә язу серләренә төшенү, ирекле темага язу. | 1 | | | |
| 36 | Нәрсә ул интервью? | 1 | | | |
| 37 | Интервью алышу. | 1 | | | |
| 38 | Муса Җәлил иҗатына карата викторина. | 1 | | | |
| 39 | Муса Җәлил шигырьләрен уку, яттан өйрәнү. | 1 | | | |
| 40 | Туган телем- татар теле” айлыгын ачу. | 1 | | | |
| 41 | Туган тел турында шигырьләр уку, яттан өйрәнү. | 1 | | | |
| 42 | Туган тел турында җырлар тыңлау, өйрәнү. | 1 | | | |
| 43 | Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 | | | |
| 44 | “ И туган тел...” (әдәби кичә) | 1 | | | |
| 45 | Әдәби викторина<br>Бишек җырларын тыңлау, туплау, өйрәнү. | 1 | | | |
| 46 | Г.Тукайга багышланган кичәгә әзерләнү. | 1 | | | |
| 47 | Г.Тукай шигырьләрен уку, яттан өйрәнү. | 1 | | | |
| 48 | Г.Тукайга багышланган сайтны күзәтү. | 1 | | | |
| 49 | Г.Тукайга багышланган кичәгә әзерләнү. | 1 | | | |
| 50 | Фәнни-гамәли конференциягә әзерләнү. | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 51 | Презентация төзү. | 1 | | | |
| 52 | Тукай укулары. | 1 | | | |
| 53 | Мәктәп китапханәсе белән берлектә кичә оештыру. Г.Тукайга – 135 ел. | 1 | | | |
| 54 | Безнең төбәктән чыккан артистларны искә алу . | 1 | | | |
| 55 | Тормыш юлы һәм иҗатына багышланган әдәби-музыкаль монтаж. | 1 | | | |
| 56 | Якташ артистларыбыз белән танышу. | 1 | | | |
| 57 | Татар халкының күренекле шәхесләре. Г.Тукай премиясе лауреатлары -2021 | 1 | | | |
| 58 | Татар халык язучылары. Юбилярлар. | 1 | | | |
| 59 | Татар халкының милли бәйрәмнәре | 1 | | | |
| 60 | Татар халкының милли гореф – гадәтләре. | 1 | | | |
| 61 | Реферат язу, аларга әзерлек. | 1 | | | |
| 62 | Данлыклы затларыбыз ( презентация карау) | 1 | | | |
| 63 | Якташ язучыларыбыз иҗатын өйрәнү. | 1 | | | |
| 64 | Безнең авылыбыз шәхесләре. | 1 | | | |
| 65 | Авыл китапханәсенә экскурсия . | 1 | | | |
| 66 | Нәрсә ул проект? | 1 | | | |
| 67 | Аны ничек әзерләргә? | 1 | | | |
| 68 | Проект эше әзерләү. | 1 | | | |
| 69 | Проект яклау. | 1 | | | |
| 70 | Эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау, йомгаклау. | 1 | | | |